АССОЦИАЦИЯ
«СОВЕТ МУНИЦИПАЛЬНЫХ
ОБРАЗОВАНИЙ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН»

«ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕКЛӘРЕ
СОВЕТЫ»
АССОЦИАЦИЯСЕ

РЕШЕНИЕ ПРЕЗИДИУМА **ПРЕЗИДИУМ КАРАРЫ**

от 10.06.2021 № ПР-17-3

г. Казань

Хуҗасыз хайваннар белән эш итү өлешендә законнарны гамәлгә ашыруның барышы турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе башлыгы А. Г. Хисаметдиновның мәгълүматын тыңлаганнан соң, «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Советы» Ассоциациясе Президиумы (алга таба – Совет) **карар кылды**:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе башлыгы А.Г. Хисаметдиновның хуҗаларсыз хайваннар белән эш итү өлешендә законнарны гамәлгә ашыруның барышы турында мәгълүматын игътибарга алырга.

2. Муниципаль районнар һәм шәһәр округлары башлыкларына тәкъдим итәргә:

2.1. хуҗаларсыз хайваннар белән эш итү өлешендә 2018 елның 27 декабрендәге «Хайваннар белән җаваплы эш итү һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» № 498-ФЗ Федераль законны тормышка ашыру буенча кичектергесез чаралар күрергә;

2.2. хуҗаларсыз хайваннар белән эш итү өлкәсендә дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга Татарстан Республикасы бюджетыннан бүлеп бирелгән финанс чараларын катгый һәм үз вакытында тотуны тәэмин итәргә;

2.3. 2021 елның беренче яртыеллыгы йомгаклары буенча, хайваннар авыруларын кисәтү һәм бетерү, аларны дәвалау, хайваннар һәм кеше өчен уртак чирләрдән халыкны яклау чараларын үткәрүне оештыру өлкәсендә дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен, 2021 елның 15 июленә кадәр муниципаль районнар һәм шәһәр округлары бюджетларына субвенцияләрне үзләштерү турында мәгълүмат бирергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тоту Советның башкарма сәркатибе А.Г.Барышевка йөкләнә.

Рәис **Э.С. Гобәйдуллин**